КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 сентябрь

г.Казань

№ 682

Футбол буенча Россия Кубогы матчын үткәрү көнендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Казан шәһәрендә «Рубин» (Казан шәһәре) – «Зенит» (Санкт-Петербург шәһәре) командалары арасында футбол буенча Россия Кубогы матчын үткәргәндә иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 30 сентябрендә әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән территорияләр чикләрендә, шулай ук Казан шәһәренең Астрономия, Бауман, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Профсоюз, Университет, Чернышевский урамнарындагы сәүдә объектларында алкогольле продукцияне ваклап сату (җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш) рөхсәт ителми дип билгеләргә.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, халыкка кертелә торган чикләү турында мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына килешү буенча йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин